| | |
|---|---|
| ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

с. Верхний Услон

______________ ______________

Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча кадастр номеры 16: 15: 040104:812 булган җир кишәрлегенә иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукларын тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турында Нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча кадастр номеры 16: 15: 040104:812 булган җир кишәрлегенә иҗтимагый фикер алышуларны билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карап тикшерү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп билгеләргә (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы).

2.2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карап тикшерү буенча җәмәгать фикер алышуларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә, 2021нче елның 5нче июленнән 2021нче елның 6нчы августына кадәр чорда оештырырга һәм үткәрергә .

2.3. Проект экспозициясен уздыру урыны - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, Татарстан Республикасы Югары Ослан

муниципаль районы Введенский Бистәсе Башкарма комитеты бинасы, 2021нче елның 5нче июленнән 2021нче елның 6нчы августына кадәр эш көннәрендә 08:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты. Тәкъдимнәр, искәрмәләр 2021нче елның 5нче июленнән 2021нче елның 6нчы августына кадәр сишәмбе көнне 08: 00 дән 12: 00 сәгатькә кадәр язма формада һәм (яки) Zakiulla.Mingazov@tatar.ru электрон почта аша кабул ителә.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыларга аларга карата проект эшләнә торган, җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларга, җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары хокукына ия булучыларга, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә ( гр.Сәетгәрәева Р. Р.) җиткерү өчен проект буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Мөрәҗәгать итүчегә (гр. Сәетгәрәева Р. Р.) иҗтимагый фикер алышуларны оештыруны, шул исәптән экспозицияләрне үткәргәндә дә техник яктан тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

5.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

5.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында урнаштырылган мәгълүмати стендта һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында проект буенча иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр урнаштырырга.

5.3. 2021нче елның 5нче июленнән дә соңга калмыйча, территорияне планлаштыру проектын һәм кадастр номеры 16:15:040104:812 булган җир кишәрлегенә территорияне межалау проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» өстәмә битендә текст формасында урнаштырырга.

5.4. Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында 2021нче елның 5нче июленнән 2021нче елның 6нчы августына кадәр эш көннәрендә 08:00 дән 12:00 гә кадәр экспозиция оештырырга.

5.5. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов